ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.08.2025 п.г.т. Алексеевское № 359

**Алексеевск муниципаль районы
территориясендә административ
хокук бозулар турында беркетмәләр
төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар
исемлеген билгеләү хакында**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китереп

**карар бирәм**:

1. Үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләргә, алар Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.1, 2.4-2.7, 2.13, 2.17, 2.19-2.22, 3.2-3.6, 3.8, 3.10, 3.11, 3.14-3.17, 4.4, 5.1, 5.2, 5.6 статьяларында каралган (кушымта).

2. Кадрлар эше өчен җаваплы затка (А.Д. Демидова) кушымта нигезендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле затларның вазыйфаи инструкцияләренә үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 08.04.2024 ел, № 128 «Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» карары, 04.09.2024 ел, № 366 «Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 08.04.2024 ел, № 128 «Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары, 28.01.2025 ел, № 21 «Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 08.04.2024 ел,

№ 128 «Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү хакында карарына үзгәрешләр кертү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_27.08.2025 ел,_ № _359_
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге**

| № | Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы (алга таба-ТР Административ хокук бозулар кодексы)статьялары исеме | Вазыйфаи затлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1 | **Статья 2.1 ТР Административ хокук бозулар кодексы** Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу (юл һәм башка күрсәткечләрне һәм билгеләрне, адрес атрибутикасын, башка визуаль мәгълүматны рәсмиләштергәндә һәм урнаштырганда телләр турында Татарстан Республикасы законнары таләпләрен үтәмәү, шулай ук телләр турында Татарстан Республикасы законнарын гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозуга яисә гражданнарның тел билгесе буенча хокукларын чикләүгә китергән башка бозу) | - Советның оештыру бүлеге башлыгы (килештерү буенча);<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| 2 | **Статья 2.4 ТР Административ хокук бозулар кодексы** Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр | - Советның оештыру бүлеге башлыгы (килештерү буенча);<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| 3 | **Статья 2.5 ТР Административ хокук бозулар кодексы** Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яисә йөртү | - Советның оештыру бүлеге башлыгы (килештерү буенча);<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| 4 | **Статья 2.6 ТР Административ хокук бозулар кодексы** Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү | - Советның баш белгеч-юристы (килештерү буенча);<br>- Советның оештыру бүлеге башлыгы |

| | | |
|---|---|---|
| | | (килештерү буенча);<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **5** | **Статья 2.7 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларын куллану тәртибен бозу | - Советның оештыру бүлеге башлыгы (килештерү буенча);<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **6** | **Статья 2.12 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булырак гражданнарны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен бозу | - Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- Советның коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе (килештерү буенча);<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **7** | **Статья 2.13 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә кую һәм исәпне алып бару тәртибен бозу | - Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- Советның коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе (килештерү буенча);<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **8** | **Статья 2.15 ТР Административ хокук бозулар кодексы 2 бүлек**<br>Терроризмны профилактикалау, аның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча коллегиаль орган карарын үтәмәү яисә бозу | - террорчылыкка каршы тору комиссиясе секретаре;<br>- Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **9** | **Статья 2.17 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19)таралуны булдырмауга һәм нәтиҗәләрен бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү | - Советның коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе (килештерү буенча);<br>- Советның оештыру бүлеге башлыгы (килештерү буенча);<br>- Советның Гомуми бүлеге башлыгы (килештерү буенча);<br>- Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары;<br>- Башкарма комитетның икътисад |

| | | |
|---|---|---|
| | | бүлеге башлыгы;<br>- Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы;<br>- «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы;<br>- «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы урынбасары;<br>- Башкарма комитетның мәдәният бүлеге җитәкчесе;<br>- Башкарма комитетның спорт бүлеге җитәкчесе;<br>- Башкарма комитетның яшьләр эшләре буенча секторы мөдире;<br>- социаль яклау бүлеге башлыгы (килештерү буенча);<br>- Башкарма комитетның архив секторы мөдире;<br>- Башкарма комитетның гомуми бүлеге башлыгы;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **10** | **Статья 2.19 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Балигъ булмаганнарга алкогольсез тынычландыручы эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итү | - балигъ булмаганнар арасында гаилә иминлеген һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча әйдәп баручы белгеч-инспектор;<br>- «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы;<br>- социаль яклау бүлеге башлыгы (килештерү буенча);<br>- Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |

| | | |
|---|---|---|
| 11 | **Статья 2.20. ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Сыекландырылган углеводород газы булган товарларны гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен балигъ булмаганнарга ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук сыеклардырылган углеводород газын сулау юлы белән балигъ булмаганнарны куллануга җәлеп итү | - балигъ булмаганнар арасында гаилә иминлеген һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча әйдәп баручы белгеч-инспектор;<br>- «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы;<br>- социаль яклау бүлеге башлыгы (килештерү буенча);<br>- Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы;<br>- Башкарма комитетның икътисад бүлеге башлыгы, белгече;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| 12 | **Статья 2.21 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Режим (база әзерлеге дәрәҗәсе) кысаларында чараларны гамәлгә ашыруны күздә тота торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү | - Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| 13 | **Статья 2.22 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Балигъ булмаганнарга автомобиль бензинын ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, транспорт чарасының ягулык бакына ягулык салганда автомобиль бензинын транспорт чарасы белән идарә итү хокукы булган уналты яшькә җиткән затларга сатудан тыш | - «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе;<br>- Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары. |
| 14 | **Статья 3.2 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Урамда сәүдә итүне оештыру һәм халыкның күңел ачуына бәйле хезмәтләр күрсәтү тәртибен бозу | Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары;<br>- Башкарма комитетның икътисад бүлеге башлыгы, белгече;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| 15 | **Статья 3.3 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Җир асты коммуникацияләрен карап тоту кагыйдәләрен бозу | - Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе |

| | | |
|---|---|---|
| **16** | **Статья 3.4 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Урамнарны, квартал эчендәге яктыртуны карап тоту кагыйдәләрен бозу | - Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **17** | **Статья 3.5 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Тышта мәгълүмат урнаштыру тәртибен бозу | - Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **18** | **Статья 3.6 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Әлеге Кодексның 3.17 статьясында каралган очраклардан тыш, җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу | - Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **19** | **Статья 3.8 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу. | - Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **20** | **Статья 3.10 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Татарстан Республикасы территориясендәге су объектларында тормышны саклау кагыйдәләрен бозу (гражданнарга карата) | - Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **21** | **Статья 3.11 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәмәү. | - Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы, белгече;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **22** | **Статья 3.14 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Мәдәни-тамаша чараларына барганда җәмәгать тәртибен бозу | - Башкарма комитетның мәдәният бүлеге җитәкчесе;<br>- Башкарма комитетның яшьләр эшләре, спорт, туризм һәм балигъ булмаганнарны профилактикалау бүлеге башлыгы; |

| | | |
|---|---|---|
| | | - «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| 23 | **Статья 3.15 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү | - Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| 24 | **Статья 3.15[1] ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Җәмәгать урыннарында товар һәм хезмәтләрне көчләп тагу | - Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- Башкарма комитетның икътисад бүлеге башлыгы, белгече;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| 25 | **Статья 3.16 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Транспорт чараларын түләүле муниципаль парковкада (парковка урыннарында)урнаштырган өчен түләмәү | - Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| 26 | **Статья 3.17 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Транспорт чараларын торак пунктлар чикләрендәге яшелләндерелгән территорияләрдә (газоннарны, чәчәклекләрне һәм үләнчел үсемлекләр биләгән башка территорияләрне кертеп), балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннар йөртү мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру | - Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- шәһәр җирлеге Башкарма комитетының әйдәп баручы белгече (килештерү буенча);<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| 27 | **Статья 4.4 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Муниципаль милектәге торак булмаган фонд объекты белән эш итү һәм күрсәтелгән объекттан файдалану тәртибен бозу | - Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| 28 | **Статья 5.1 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Билетсыз йөрү | - Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары; |

| | | |
|---|---|---|
| | | - «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **29** | **Статья 5.2 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Багаж ташу кагыйдәләрен бозу | - Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |
| **30** | **Статья 5.6 ТР Административ хокук бозулар кодексы**<br>Пассажирны йөртүдән баш тарту (тиешле муниципаль берәмлекләр территорияләрендә башкарыла торган муниципаль ташуларга карата) | - Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары;<br>- «ТР АМР АТИ» МКУ җитәкчесе. |